**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

20. 1 1. 2018 — _______

2018 елга «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәткә тарифны раслау турында

Актаныш муниципаль районы Советының 2007 елның 12 гыйнварындагы 12-2 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Советы һәм учреждениеләре товарларына, эш һәм хезмәт күрсәтүләренә бәяләр, тарифлар билгеләү тәртибенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең һәм учреждениеләренең 2018 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы хезмәт күрсәтүләренә тарифларны (бәяләрне) карау буенча комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә һәм керем китерә торган оешмаларда эшчәнлекне тәртипкә салу максатларында,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 1 нче кушымта нигезендә “Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе” өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенең түләүле хезмәтләре исемлеген һәм тарифын расларга.
2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе директорына ведомство карамагындагы муниципаль бюджет учреждениесендә расланган тарифны куллануны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Актаныш муниципаль районы сайтында түбәндәге адрес буенча: http//Aktanysh.tatarstan.ru/ бастырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны икътисад буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче — И.Ш. Бариев

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарына_____2018 ел,№___

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Дулкын» бассейны «Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе»муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә күрсәтелә торган түләүле хезмәт күрсәтү тарифы

| Түләүле хезмәт төре | Бер тренировка дәресе өчен түләү-сумнарда | Уку өчен бер айга 12 сәгать өчен, сумнарда түләү |
|---|---|---|
| Йөзү буенча күнегүләр программасы нигезендә, өч айга 36 сәгать укыту программасы буенча | 100 | 1200 |